КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 9 декабрь г.Казань № 1206

Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне;

хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүнең яңа системасы билгеләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары исемлеген.

2. Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары хезмәткәрләренең бу карар нигезендә билгеләнә торган эш хакы, хезмәткәрләрнең вазифаи бурычлары күләме сакланса һәм алар шул ук квалификациядәге эшләрне башкарса, бу карар нигезендә хезмәт өчен түләүнең яңа шартларына күчкән вакытта гамәлдә булган хезмәт өчен түләү системасы нигезендә түләнә торган эш хакыннан ким була алмый дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары җитәкчеләренә, хезмәткәрләрнең тиешле һөнәр берлекләре органы белән килештереп:

Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартларын билгели торган коллектив шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив актларга тиешле үзгәрешләрне кертергә;

Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары хезмәткәрләренә, бу карар белән билгеләнгән хезмәт өчен түләү системасын керткәнгә кадәр ике айдан да соңга калмыйча, хезмәт шартнамәсенең җитди шартларына үзгәреш кертү турында хәбәр итәргә.

4. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2013 ел, 31 июль, 538 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2013 ел, 31 июль, 538 нче карары белән расланган Хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүнең яңа системасы билгеләнә торган фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе дәүләт учреждениеләре исемлегенә үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 17 март, 159 нчы карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2013 ел, 31 июль, 538 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 30 декабрь, 1056 нчы карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2013 ел, 31 июль, 538 нче карары белән расланган Фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 18 сентябрь, 696 нчы карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2013 ел, 31 июль, 538 нче карары белән расланган Фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 7 сентябрь, 793 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 26 июль, 645 нче карарындагы 3 пункты.

5. Бу карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән бүлегенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин